СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

30.09.24г№ 49/3

На №__________от______________

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә планлаштырылган (күздә тотылган) хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында**

Казан районара табигатьне саклау прокуратурасының 2023 елның 22 декабрендәге 02-07-2023/прдп644 номерлы протестын карап, «Экологик экспертиза турында» 1995 елның 23 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы , «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварендагы 7-ФЗ номерлы , «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законнарга, Россия Федерациясе Табигый ресурслар һәм экология министрлыгының 2020 елның 1 декбрендәге «Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү материалларына таләпләрне раслау турында» 999 номерлы боергына таянып, муниципаль берәмлек Советы

## КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә планлаштырылган (күздә тотылган) хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне расларга.
2. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Тукай муниципаль районы Советының 2019 елның 29 мартындагы 31/10 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы,
Совет Рәисе урынбасары

Совет Тукаевского муниципального района

Р.И. Закиров

Тукай муниципаль районы Советының 2024 елның 30 сентябрендәге 49/3 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә планлаштырылган (күздә тотылган) хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә планлаштырылган (күздә тотылган) хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибе турында әлеге нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә күздә тотылган, экология экспертизасы узарга тиешле хуҗалык һәм башка эшчәнлек һәм аның әйләнә-тирә мохиткә мөмкин булган йогынтысы турында иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру тәртибен билгели (алга таба – Тәртип).

1.2. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

- күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек – әйләнә-тирә мохиткә турыдан-туры яисә читләтеп йогынты ясый ала торган эшчәнлек;
- заказчы – күздә тотылган эшчәнлек буенча документацияне әлеге эшчәнлек төренә куела торган норматив таләпләр нигезендә әзерләү өчен җавап бирүче һәм күздә тотылган эшчәнлек буенча экология һәм дәүләт экспертизасына документация тапшыручы юридик яисә физик зат;
- әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү эшләрен башкаручы – әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүне башкаручы физик яки юридик зат (заказчы әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү эшләрен уздыру хокукын биргән заказчы яки физик (юридик) зат);
- йогынтыны бәяләү буенча тикшеренүләр – йогынтыны бәяләү максатларын гамәлгә ашыру өчен кирәкле мәгълүматны җыю, анализлау һәм документлаштыру;
- әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү материаллары – күздә тотылган эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләүне уздырганда әзерләнгән һәм күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекне нигезли торган, шул исәптән экология экспертизасына тапшырыла торган документациянең бер өлеше булган документлар комплекты;
- күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү – күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең, аны гамәлгә ашыру мөмкинлеге яки мөмкин булмавы турында карар кабул итү максатында, әйләнә-тирә мохиткә йогынтысының турыдан-туры, читләтеп һәм башка нәтиҗәләрен ачыклау, анализлау һәм исәпкә алу буенча эшчәнлек төре;
- иҗтимагый фикер алышулар – әлеге Тәртип һәм күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек, аның әйләнә-тирә мохиткә йогынтысы ихтималлыгы турында башка норматив документлар нигезендә җәмәгатьчелеккә хәбәр итүгә юнәлтелгән, җәмәгатьчелекнең катнашуын тәэмин итү, йогынтыны бәяләүне уздыру барышында иҗтимагый өстенлекләрне ачыклау һәм аларны исәпкә алу максатында үткәрелә торган чаралар комплексы;

- җәмәгатьчелек – мәнфәгатьләренә күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек, аның әйләнә-тирә мохиткә мөмкин булган йогынтысы турыдан-туры яисә читләтеп кагылырга мөмкин булган гражданнар, аларның берләшмәләре, шул исәптән территориаль үзидарә органнары, юридик затлар;
- экология экспертизасы – экология экспертизасы объектын гамәлгә ашыруга бәйле рәвештә күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлекне нигезли торган документларның һәм (яки) документациянең техник регламентларда һәм әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнарда билгеләнгән экология таләпләренә туры килүен мондый эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынтысын булдырмау максатында билгеләү.

1.3. Иҗтимагый фикер алышулар әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү процессының аерылгысыз өлеше булып тора һәм түбәндәге максатларда үткәрелә:

- кешенең уңайлы әйләнә-тирә мохиткә хокукларын үтәү;
- кешенең тормыш эшчәнлегенә уңайлы шартлар тәэмин итү;
- җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең законлы хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү;
- планлаштырылган (күздә тотылган) хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашырган очракта, әйләнә-тирә мохиткә мөмкин булган тискәре йогынтыларны һәм аларга бәйле социаль, икътисадый һәм башка нәтиҗәләрне булдырмау (кисәтү) яисә киметү (йомшарту);
- әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү процессында халыкның төрле төркемнәре мәнфәгатьләрен исәпкә алу һәм иҗтимагый өстенлекләрне ачыклау һәм аларны исәпкә алу;
- планлаштырылган (күздә тотылган) хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында карарлар кабул иткәндә ачыклык һәм җаваплылык тәэмин итү;
- бәхәсле мәсьәләләрне иртә ачыклау юлы белән конфликтлыкны киметү.

Иҗтимагый фикер алышуларда барлык кызыксынган затлар, шул исәптән: гражданнар, иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр), дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары вәкилләре, экспертлар катнаша ала.

Иҗтимагый фикер алышулар процедурасы чаралар комплексын үз эченә ала, шул исәптән: күздә тотылган хуҗалык һәм башка эшчәнлек турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат җиткерү, иҗтимагый фикер алышулар үткәрү, җәмәгатьчелекнең искәрмәләрен һәм тәкъдимнәрен җыю һәм анализлау.

Әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү материалларын әзерләгәндә, җәмәгатьчелекнең катнашуы гамәлгә ашырылырга мөмкин:

- техник бирем проектын әзерләү этабында;
- әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү буенча беренчел материаллар буенча фикер алышу этабында.

Җәмәгатьчелек катнашындагы барлык карарлар документаль рәвештә рәсмиләштерелә.

1.4. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә планлаштырылган (күздә тотылган) хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә мохиткә йогынтысын бәяләү буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру өчен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының вәкаләтле органы булып Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге (алга таба – вәкаләтле орган) тора.

## 2. Планлаштырылган (күздә тотылган) хуҗалык һәм башка эшчәнлек буенча иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру

2.1. Иҗтимагый фикер алышулар түбәндәге формаларда уздырыла:
- гади мәгълүмат бирү (хәбәрнамә нигезендә җәмәгатьчелеккә иҗтимагый фикер алышу объектының урнашу урынын күрсәтеп һәм адрес (адреслар) буенча, шул исәптән электрон почта аша искәрмәләр, комментарийлар һәм тәкъдимнәр җыеп хәбәрнамә нигезендә, җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү);
- сораштыру (урнаштыру урынын күрсәтеп, иҗтимагый фикер алышулар объекты, сораштыру кәгазьләре формасында җәмәгатьчелекнең искәрмәләрен, комментарийларын һәм тәкъдимнәрен җыю тәртибе һәм сораштыру беркетмәсен рәсмиләштерү белән танышу өчен җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү);
- иҗтимагый тыңлаулар (иҗтимагый фикер алышулар объектын таныштыру өчен урнаштыру урынын, иҗтимагый тыңлаулар үткәрү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, җәмәгатьчелеккә хәбәр итү, теркәү кәгазьләрен һәм иҗтимагый тыңлаулар беркетмәләрен рәсмиләштерү);
- фикер алышу өчен материалларны урнаштыру урынын күрсәтеп һәм искәрмәләр, комментарийлар һәм тәкъдимнәр җыеп (конференция, түгәрәк өстәл, анкеталаштыру, җәмәгатьчелек белән консультацияләр, шулай ук әлеге пунктта күрсәтелгән формаларны берләштерү) иҗтимагый фикер алышулар объекты белән танышу һәм иҗтимагый фикер алышулар объекты буенча искәрмәләр, комментарийлар һәм тәкъдимнәр алу.

2.2. Иҗтимагый фикер алышулар объекты булып техник бирем проекты, шулай ук дәүләт экология экспертизасы объекты һәм (яки) әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү материалларының беренчел варианты (алга таба – бәяләү материаллары) тора.

2.3. Иҗтимагый фикер алышуларның түбәндәге этаплары була:
- хәбәрнамә бирү;
- иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү турында карар кабул итү;
- иҗтимагый фикер алышуларны әзерләү һәм оештыру;
- иҗтимагый фикер алышулар үткәрү;
- иҗтимагый фикер алышуларга нәтиҗәләр ясау (планлаштырылган (күздә тотылган) хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыру буенча нәтиҗәләр һәм тәкъдимнәр), беркетмә төзү.

2.4. Иҗтимагый фикер алышуларны уздыруның дәвамлылыгы хәбәрнамәдә күрсәтелгән адрес буенча җәмәгатьчелекнең иҗтимагый фикер алышулар объектыннан (иҗтимагый фикер алышулар объектын урнаштыру) файдалана алуын тәэмин иткән көннән алып:
- техник бирем проекты буенча – кимендә 10 календарь көн;
- бәяләүнең беренчел материаллары (яки экологик экспертиза объекты, әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүнең беренчел материалларын да кертеп) буенча – кимендә 30 календарь көн (иҗтимагый тыңлаулар уздыру көннәрен исәпкә алмыйча) тәшкил итә.

2.5. Заказчы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба – Башкарма комитет) әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү материалларын формалаштыру этабына, техник бирем проектына яисә бәяләүнең беренчел материаллары проектына бәйле рәвештә иҗтимагый фикер алышулар уздыру турында хәбәрнамә җибәрә.

2.6. Хәбәрнамәдә күрсәтелә:

- әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү буенча эшләрнең заказчысы һәм башкаручысы (исеме – юридик затлар өчен; фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта) – шәхси эшмәкәрләр өчен; төп дәүләт теркәү номеры (ОГРН) яки шәхси эшмәкәрнең төп дәүләт теркәү номеры (ОГРНИП); юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр өчен өчен салым түләүченең шәхси номеры (ИНН) ; юридик һәм (яки) фактик адрес – юридик затлар өчен; яшәү урыны адресы – шәхси эшмәкәрләр өчен; контакт мәгълүматы (телефон, электрон почта адресы (булган очракта), факс (булган очракта);
- иҗтимагый фикер алышулар оештыру өчен җаваплы җирле үзидарә органының исеме, юридик һәм (яки) фактик адресы, контакт мәгълүматы (телефон һәм электрон почта адресы (булган очракта), факс (булган очракта);
- планлаштырылган (күздә тотылган) хуҗалык һәм башка эшчәнлек исеме;
- планлаштырылган (күздә тотылган) хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең максаты;
- планлаштырылган (күздә тотылган) хуҗалык һәм башка эшчәнлекне гамәлгә ашыруның беренчел урыны;
- әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләүне уздыруның планлаштырылган сроклары;
- иҗтимагый фикер алышу объектыннан файдалану урыны һәм сроклары;
- иҗтимагый фикер алышулар уздыруның фаразланган формасы һәм вакыты, шул исәптән искәрмәләр һәм тәкъдимнәр тапшыру формасы (җәмәгать тыңлаулары формасында иҗтимагый фикер алышулар уздырылган очракта, җәмәгать тыңлауларын уздыру датасы, вакыты, урыны күрсәтелә; иҗтимагый фикер алышулар сораштыру формасында уздырылган очракта, сораштыру үткәрү сроклары, шулай ук сораштыру кәгазьләрен урнаштыру һәм җыю урыны күрсәтелә (әгәр ул җәмәгать тыңлаулары объектын урнаштыру урыныннан аерылса), шул исәптән электрон рәвештә);
- заказчы (башкаручы) һәм җирле үзидарә органы ягыннан җаваплы затларның контакт мәгълүматлары (телефон һәм электрон почта адресы (булганда);
- заказчы (башкаручы) теләге буенча башка мәгълүмат.

2.7. Башкарма комитет иҗтимагый фикер алышулар уздыру турында хәбәрнамәне карый һәм хәбәрнамә теркәлгән көннән алып 14 эш көне эчендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башлыгы иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү турында яисә иҗтимагый фикер алышуларны билгеләүдән дәлилләп баш тарту турында карар кабул итә.

Иҗтимагый фикер алышуларны билгеләүдән баш тарту өчен нигез булып заказчының хәбәрнамәдә тулы булмаган һәм (яисә) дөрес булмаган мәгълүмат бирүе тора.

Иҗтимагый фикер алышуларны билгеләү турында карар кабул ителгәннән соң, иҗтимагый фикер алышулар уздыру турында хәбәрнамә вәкаләтле органга башкаруга тапшырыла.

2.8. Иҗтимагый фикер алышулар уздыру турында карар Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башлыгы карары белән рәсмиләштерелә, анда күрсәтелә:
- иҗтимагый фикер алышулар уздыру датасы, вакыты һәм урыны;
- иҗтимагый фикер алышулар уздыру формасы;
- иҗтимагый фикер алышулар объекты;
- иҗтимагый фикер алышулар объекты белән танышу мөмкин булган дата;
- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә планлаштырылган (күздә тотылган) хуҗалык һәм башка эшчәнлекнең әйләнә-тирә

мохиткә йогынтысын бәяләү кысаларында үткәрелә торган иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру комиссиясе турында нигезләмә нигезендә әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү кысаларында иҗтимагый фикер алышуларны оештыру һәм уздыру өчен җаваплы комиссия составы (алга таба – Комиссия);
- танышу өчен иҗтимагый фикер алышулар объекты буенча материаллар урнаштыру урыны;
- искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү өчен адреслар һәм контакт мәгълүматлары.
2.9. Вәкаләтле орган җәмәгатьчелеккә иҗтимагый фикер алышулар уздыру турында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында https://tukay.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча иҗтимагый фикер алышулар уздыру турында хәбәрнамә урнаштыру юлы белән хәбәр итә.

Иҗтимагый фикер алышулар уздыру турында хәбәрнамә җәмәгатьчелекне таныштыру өчен иҗтимагый фикер алышулар объектыннан файдалану мөмкинлеген тәэмин итү датасыннан исәпләнә торган планлаштырылган иҗтимагый фикер алышу башланырга 3 календарь көннән дә соңга калмыйча басылып чыгарга тиеш.
2.10. Өстәмә мәгълүмат бирү вакытлы матбугатта, мәгълүмат стендларында, Интернет мәгълүмат-коммуникация челтәре аша мәгълүмат тарату юлы белән, шулай ук мәгълүмат таратуны тәэмин итә торган башка ысуллар белән гамәлгә ашырылырга мөмкин.
2.11. Җәмәгатьчелектән язма искәрмәләр һәм тәкъдимнәр җәмәгатьчелек тәкъдимнәрен һәм искәрмәләрен исәпкә алу журналында кабул ителә һәм теркәлә.
2.12. Җәмәгатьчелекнең искәрмәләре һәм тәкъдимнәре җәмәгать фикер алышулары процедурасын үткәрүнең бөтен чоры дәвамында шул исәптән хәбәрнамәдә күрсәтелгән электрон почта аша да кабул ителергә мөмкин.

## 3. Җәмәгать тыңлаулары формасында иҗтимагый фикер алышулар уздыру тәртибе

3.1. Җәмәгать тыңлаулары формасында иҗтимагый фикер алышулар гавами чараны транспорт уңайлылыгында урнашкан махсус билгеләнгән урында уздыруны күздә тота. Җәмәгать тыңлаулары уздыру чорына бина техник җиһазлар (микрофоннар, тавыш җиһазлары) белән тәэмин ителергә тиеш.
3.2. Җәмәгать тыңлаулары җәмәгатьчелекне җәмәгать тыңлаулары темасы буенча материаллар белән алдан таныштыруны күздә тота.
3.3. Җәмәгать тыңлаулары башланырга өч көн кала заказчы вәкаләтле органга түбәндәге мәгълүматны тапшыра:
- җәмәгать тыңлаулары темасы буенча докладчылар (өстәмә докладчылар) исемлеге;
- җәмәгатьчелектән килгән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне гомумиләштерү нигезендә әзерләнгән дәлилле җаваплар.
3.4. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны теркәү таблица формасында рәсмиләштерелә торган һәм түбәндәгеләрне үз эченә алган теркәү кәгазьләрендә чара башланырга 30 минут кала башлана:
а) җәмәгать тыңлаулары объекты исеме;
б) җәмәгать тыңлауларын үткәрү датасы, урыны;
в) җәмәгать тыңлауларында катнашучының теркәү номеры;
г) җәмәгать тыңлауларында катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта);

д) адрес, телефон (физик затлар өчен – яшәү урыны адресы һәм телефон, оешмалар вәкилләре өчен – урнашу урыны адресы һәм оешма телефоны);
е) оешма исеме (оешмалар вәкилләре өчен);
ж) имза, шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык (җәмәгать тыңлаулары дистанцион форматта уздырылган очракта имзалар булмый).

Теркәлгәндә җәмәгать тыңлауларында катнашучыга иҗтимагый фикер алышуларда катнашучының теркәү картасы бирелә, аның ярдәмендә җәмәгать тыңлауларында катнашучы докладчыга сорау бирә яисә чыгышлар өчен регламентта билгеләнгән вакытта чыгыш ясарга гариза бирә ала. Теркәү картасы иҗтимагый фикер алышулар секретарена теркәү һәм аны иҗтимагый фикер алышулар рәисенә тапшыру өчен бирелә, ул докладчылар чыгышлары барышында кергән сорауларны игълан итәчәк һәм/яки мөрәҗәгать итүчегә чыгышлар өчен регламентта билгеләнгән вакытта чыгыш ясау өчен сүз бирәчәк.

3.5. Зат исеменнән ышанычнамәсез эш итәргә хокуклы затларның оешмалар исеменнән катнашуы мөмкин, башка затларның тиешле оешмаларның мәнфәгатьләрен яклауга ышанычнамәсе булырга тиеш.

3.6. Җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны теркәү кәгазе җәмәгать тыңлаулары беркетмәсенең аерылгысыз өлеше булып тора.

3.7. Иҗтимагый фикер алышулар рәисе (Комиссия рәисе) заказчы (башкаручы) белән берлектә җәмәгать тыңлауларын үткәрә.

3.8. Иҗтимагый фикер алышулар рәисе:
- җәмәгать тыңлауларын ача, үзен, секретарне һәм җәмәгать тыңлауларында катнашучыларны тәкъдим итә, җәмәгать тыңлауларының темасын һәм көн тәртибен игълан итә;
- җәмәгать тыңлауларында катнашучыларга җәмәгать тыңлауларын уздыру регламентын җиткерә;
- теркәлү узган җәмәгать тыңлауларында катнашучылар саны турында хәбәр итә;
- җәмәгать тыңлауларын алып бара, тыңлаулар үткәрү регламентының һәм тәртибенең үтәлешен күзәтә;
- җәмәгать тыңлауларында тәнәфес игълан итү, шулай ук аны башка көнгә күчерү турында карарлар кабул итә;
- җәмәгать тыңлауларын уздыруны катнашучылар хокукка каршы гамәлләр кылган очракта туктатырга хокуклы;
- регламентны яки җәмәгать тәртибен бозган һәм җәмәгать тыңлауларын оештыручының законлы таләпләренә буйсынмаган затны җәмәгать тыңлаулары урыныннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

3.9. Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар хокуклы:
- җәмәгать тыңлауларын уздыру регламентын үзгәртү турында тәкъдимнәр кертергә;
- докладчыларга сораулар бирергә;
- җәмәгать тыңлаулары объектына карата искәрмәләр, сораулар һәм тәкъдимнәрне телдән һәм (яисә) язма формада тапшырырга;
- регламент белән билгеләнгән вакыт эчендә докладлар һәм чыгыш ясарга;
- җәмәгать тыңлаулары беркетмәсенә кул кую өчен җәмәгатьчелек вәкилләрен тәкъдим итәргә;
- гамәлдәге законнар һәм чара регламенты кысаларында башка гамәлләрне башкарырга.

3.10. Җәмәгать тыңлауларында катнашучылар бурычлы:
- җәмәгать тәртибен һәм җәмәгать тыңлаулары уздыру регламентын үтәргә.

3.11. Җәмәгать тыңлауларында җәмәгать тыңлауларын уздыру беркетмәсенә имза кую өчен гражданнар һәм иҗтимагый оешмалар (берләшмәләр) вәкилләре сайланырга мөмкин.
3.12. Җәмәгать тыңлауларында беркетмә һәм массакүләм мәгълүмат чараларында публикацияләр рәсмиләштерү максатыннан, барлык чыгышлар һәм фикер алышуларның аудио һәм видеоязмасы башкарылырга мөмкин.
3.13. Җәмәгать тыңлаулары формасында иҗтимагый фикер алышулар тәмамланганнан соң, 5 эш көне эчендә җәмәгать тыңлаулары беркетмәсе төзелә, анда түбәндәгеләр күрсәтелә:
- җәмәгать тыңлаулары объекты;
- җәмәгать тыңлауларын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү ысулы;
- җәмәгать фикер алышуы объекты буенча материаллардан җәмәгатьчелеккә файдалану мөмкинлеге урыны (шул исәптән заказчы карары буенча Интернет челтәрендә) һәм вакыты, ләкин җәмәгать тыңлаулары уздырыла торган көнгә кадәр кимендә 20 календарь көн кала һәм җәмәгать тыңлаулары уздырылган көннән соң 10 календарь көн;
- җәмәгать тыңлауларын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;
- җәмәгать тыңлауларында катнашучыларның гомуми саны;
- җәмәгать тыңлауларында фикер алышына торган сораулар;
- җәмәгатьчелек һәм заказчы (башкаручы) арасында каршылыклар предметы (ул булган очракта);
- җәмәгатьчелек фикерен исәпкә алуны детальләштерүче башка мәгълүмат.
3.14. Беркетмә вәкаләтле орган тарафыннан рәсмиләштерелә һәм иҗтимагый фикер алышулар рәисе, заказчы (башкаручы), җәмәгатьчелек вәкилләре тарафыннан имзалана.
3.15. Җәмәгать тыңлаулары нәтиҗәләре турында мәгълүмат (беркетмә) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында https://tukay.tatarstan.ru/ веб-адресы буенча урнаштырыла.
3.16. Җәмәгать тыңлаулары беркетмәсе әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү материаллары составына керә.

## 4. Сораштыру формасында иҗтимагый фикер алышулар уздыру тәртибе

4.1. Иҗтимагый фикер алышуларга чыгарылган материалларга карата искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне кабул итү һәм таныштыру кимендә 30 календарь көндә (сораштыру үткәрү вакытына кадәр кимендә 10 календарь көн кала һәм сораштыру үткәрү вакытыннан кимендә 10 календарь көн) гамәлгә ашырыла.
4.2. Сораштыруны үткәрү вакыты 10 календарь көн тәшкил итә.
4.3. Сораштыру иҗтимагый фикер алышуларына чыгарылган материалларны урнаштыру адресы буенча яисә иҗтимагый фикер алышулар уздыру турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән башка адрес буенча сораштыру кәгазьләрен җыю юлы белән, шулай ук иҗтимагый фикер алышулар уздыру турында хәбәрнамәдә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча сораштыру кәгазьләрен җыю юлы белән үткәрелә.
4.4. Сораштыру кәгазьләрендә сорауларның формулировкалары төгәл һәм ачык булырга һәм аларны төрлечә аңлату мөмкинлегенә юл куймаска, шулай ук

иҗтимагый фикер алышуларга чыгарыла торган мәсьәләнең асылы буенча булырга тиеш.

4.5. Сораштыру кәгазендә аны тутыру тәртибе турында аңлатмалар булырга тиеш.

4.6. Сораштыруда территориясендә хуҗалык эшчәнлеге планлаштырылган (күздә тотылган) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында яшәүчеләр генә катнаша ала.

4.7. Сораштыру кәгазе сораштырылучы (сораштыруны дистанцион форматта уздыру очракларыннан тыш), заказчы (башкаручы) вәкиле һәм иҗтимагый фикер алышулар секретаре тарафыннан тутырыла һәм имзалана.

4.8. Сораштыру тәмамланганнан соң, комиссия әгъзалары сораштыру нәтиҗәләрен сораштыру кәгазьләрендәге (җәмәгатьчелектән кергән искәрмәләрне һәм тәкъдимнәрне исәпкә алу журналындагы) күрсәткечләрне эшкәртү юлы белән саныйлар һәм сораштыру тәмамланганнан соң, 5 эш көне эчендә беркетмә төзиләр, анда түбәндәге күрсәткечләр күрсәтелә:

- сораштыру объекты;
- сораштыру үткәргәндә тәкъдим ителә торган сорауның формулировкасы;
- сораштыруны үткәрү сроклары, сораштыру кәгазьләрен урнаштыру һәм җыю урыны турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү ысулы, шул исәптән электрон рәвештә;
- алынган сораштыру кәгазьләренең саны;
- гамәлгә яраксыз дип танылган сораштыру кәгазьләренең саны;
- сораштыру нәтиҗәләре, куелган мәсьәләләргә өстәмә позицияләрне, иҗтимагый фикер алышулар объекты буенча ачыкланган кисәтүләрне, тәкъдимнәрне һәм комментарийларны да кертеп.

Заказчы (башкаручы) вәкиле һәм иҗтимагый фикер алышулар секретаре тамгалары (имзалары) булмаган билгесез үрнәктәге сораштыру кәгазьләре, шулай ук дәүләт экология экспертизасы объектына карата сораштыруда катнашучыларның фикерен төгәл билгеләү мөмкин булмаган сораштыру кәгазьләре гамәлгә яраксыз дип танылa.

4.9. Сораштыру беркетмәсенә иҗтимагый фикер алышулар рәисе һәм заказчы (башкаручы) вәкиле имза куя, сораштыру кәгазьләре беркетмәгә теркәлә.

4.10. Уздырылган сораштыру нәтиҗәләре турында мәгълүмат Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында https://tukay.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән җәмәгатьчелеккә җиткерелә.

4.11. Сораштыру беркетмәсе әйләнә-тирә мохиткә йогынтыны бәяләү материаллары составына керә.

4.12. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башлыгы иҗтимагый фикер алышуларны башка формаларда (җәмәгать тыңлаулары яисә сораштыру формасында түгел) билгеләү турында карар кабул иткәндә, аларны үткәрү тәртибе Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башлыгы карары белән билгеләнә.